Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.12.2022 ел Менделеевск ш. №229

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
муниципаль берәмлекләренең
чикләрен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясына, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы», муниципаль берәмлек уставына ярашлы

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Менделеевск шәһәре» һәм «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү инициативасы белән «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләренә кергән җир кишәрлекләрен «Татар Чаллысы авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенә кертү (1 нче кушымта), шулай ук «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы чигенә туры китереп, Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш итеп китерү инициативасы белән чыгарга (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү буенча фикер белдерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru , шулай ук Монашево, Татар Чаллысы авыл җирлекләренең мәгълүмати стендларында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе Р.И. Беляев

“Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
муниципаль берәмлекләренең
чикләрен үзгәртү турында”
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Советының 2023 елның 18 декабрендәге
229 номерлы карарына 1 кушымта

**Карта-схема**
границ муниципальных образований
с учетом изменений



“Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
муниципаль берәмлекләренең
чикләрен үзгәртү турында”
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Советының 2023 елның 18 декабрендәге
229 номерлы карарына 2 кушымта

